# КӨМЕШ ТОЯК ТУЛПАР АТЫМ

*МАРС МАКАРОВ музыкасы*
*Халык сүзләре*

Туп-туп кына басып килә
Көмеш тояк тулпар атым, һай!
Канатланып үзем киләм,
Җитмәс, диеп, язган хатым.

Атым килә туп-туп атлап.
Ташлы юлларны таптап, һай!
Сагынганда карар идем,
Карурман тора каплап.

Бергә чаклар искә төшә,
Казан, диеп бер җырласам, һай!
Кемне сагынып җырлар идем,
Казаннарда син булмасаң.

Туп — туп кына басыл килә
Көмеш тояк тулпар атым, һай!
Канатланып үзем киләм,
Җитмәс, диеп, язган хатым